# Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге составына керүче Яңа Тинчәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре

19.11.2025 № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Яңа Тинчәле авыл җирлегенең Яңа Тинчәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Яңа Тинчәле авылында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), - торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, договор буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), хуҗасыз йорт хуҗалыкларын койма белән әйләндереп алу өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2025 елның 19 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 400 катнашучы кертелде. Тавыш бирүдә катнашучылар саны-225 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 225 кеше «әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлегенең Яңа Тинчәле авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Яңа Тинчәле авыл җирлегенең Яңа Тинчәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Яңа Тинчәле авылында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), - торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, договор буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), хуҗасыз йорт хуҗалыкларын койма белән әйләндереп алу өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Яңа Тинчәле авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Тинчәле авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: __________ Р.К. Мадышев

Яңа Тинчәле авыл җирлеге
башлыгы __________________ Р.К. Мадышев